Казан шәһәре Мәскәү районының “105нче татар телендә белем һәм тәрбия бирүче катнаш төрдәге балалар бакчасы

**« Куянкай һәм аның дуслары маҗаралары”**

**Зурлар төркемендә куркынычсызлык кагыйдәләре буенча театральләштерелгән   танып-белү эшчәнлеге.**

**Тәрбияче:** Бикмиева Г.Г.

Казан 2017

**Эчтәлек**

1. Кереш......................................................................................................3
2. Эшчәнлек барышы.....................................................................................4
3. Йомгаклау.................................................................................................9
4. Кулланылган әдәбият исемлеге................................................................10

## Кереш

Балалар тормышта төрле куркынычлар белән очрашып тора. Мондый очракларда, чишелеш таба алмыйча югалып калмасыннар өчен, балалар белән куркынычсызлык кагыйдәләрен кабатлап тору кирәк. Әкият формасында оештырылган эшчәнлек барышында, балалар бу кагыйдәләрне уйнап күрсәтәләр һәм куркынычсызлык очракларында үзләрен ничек тотарга кирәклеген өйрәнәләр.

**Максат:** театр эшчәнлеге аша балаларда көндәлек томышта куркынычсызлык кагыйдәләре турында белемнәр формалаштыру.

**Бурычлар:**

- балаларны әкият геройлары аша элементар куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү;
- балаларны куркыныч ситуацияләрне таный белергә өйрәтү;
- куркыныч килеп туган очраклардакыен хәлдән чыгу юлларын табу күнекмәләрен булдыру;
- экстремаль очракларда үз-үзләрен дөрес тоту күнекмәләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** җәнлекләр костюмнары, ялкын макеты, янгын сүндерүчеләр өчен чиләкләр, шәм, таблетка, розетка, кадак муляжлары.

**Катнашалар:** әни куян, бала куян, әтәч, хат ташучы, тавык, төлке, эт, тиен, аю балалары.

**Эшчәнлек барышы**

Өйдә әни куян һәм куян баласы утыра.

**Тәрбияче:**

Бер урман аланында,

Нәни урман йортында

Яшәгән ди, торган ди куянкай һәм куян әни.

Аларга көн дә, көн дә

кунаклар бик күп килә. (җәнлекләр керә)

Бу – урман җәнлекләре:

тиен, эт, аю,тавык һәм төлке.

Иртән әни куян эшләре белән китә

Һәм балаларга әйтә:

**Әни куян:**

Балаларым, мин эшкә китәм, кишерләргә, кәбестәләргә су сибеп кайтам. Ә сез матур гына уйнагыз. Ишекне бикләгез дә, беркемне дә кертмәгез.

**Тиен:** Дусларым, мин бик кызык уен алып килдем, әйдәгез уйныйбызмы?

**Тәрбияче:** Җәнлекләр, әйдәгез карыйк әле. Тиен безгә нинди уен алып килде икән? Монда саннар һәм рәсемнәр. Биремнәре дә бар икән. Әйдәгез,мин сезгә табышмаклар әйтәм, ә сез, дөрес җавап белән карточкаларны күтәрәсез.

1. Гомер бу яшәгән,

   Беркемгә сүз дәшмәгән.

   Ләкин аңа карыйлар,

   Бер сүзсез дә аңлыйлар. (Светофор)

2. Кабына кгылдыңмы, кабына. (шырпы)

3. Төтен күрдеңме, тизрәк чакыр. (янгын сүндерүчеләр)
4. Янгын сүндерүчеләрне чакырыр өчен нинди номерны җыябыз? (01)
5. Ашыгыч ярдәмне кайсы номер буенча чакырабыз?(03)
6. Полицияне нинди номерга шалтыратып чакырабыз?(02)
7. Исе юк, төсе юк,

   Аннан башка тормыш юк. (Су)
8. Башы белән кабына,

   Кагылдыңмы, кабына. (Шырпы)
9. Үзе өрми, теле бар,

   Үзенең теше юк, ләкин тешли. (Ут)
10. Башыбыз бар, гәүдәбез бар,

    Юк кул, аякларыбыз.

    Балалар тотса, куркабыз –

    Яман шул якларыбыз. (Шырпы)
11. Зур ялкынны да,

    Кечкенә генә утны да,

    Су сибә дә сүндерә.

    Кем була ул? Кем әйтә? (Янгын сүндерүче)

**Тәрбияче**: Рәхмәт сиңа, тиен. Бик файдалы уен алып килгәнсең син. Төлке, сиңа уен ошадымы?

**Төлке:** Миңа бу уен бер дә ошамады. (төлке шкаф янына килеп, ишеген ача)

**Тәрбияче:** балалар, ә сезгә ошадымы уен?

**Тәрбияче:** Төлке баласы шкаф ишеген ача. Ә анда: мамык, бинт, төрле-төрле таблеткалар, төрле-төрле банкалар.

**Төлке:** уууу, монда никадәр матур әйберләр. Ничек кызык. Нинди генә таблеткалар юк монда. Ә бәлки, бу – витаминдыр? Ашап карыйм әле. Ә аннары дусларымны сыйлармын.

**Куян баласы:** Нишлисең, төлке, куй даруларны! Син кечкенә түгел бит инде. Белергә тиеш: дарулар белән уйнарга ярамый. Беркайчан да әниең бирмәгән даруны кабарга ярамый.

**Тәрбияче:** Балалар, ни өчен дарулар белән уйнарга ярамый?

**Төлке:** Әйе, исемдә калдырдым. Дарулар – уенчык түгел.

(ишек шакыган тавыш, җәнлекләр ишеккә йөгерәләр)

**Барсы бергә:** Әниең кайтты, әни куян кайтты.

**Эт:** Туктагыз, дусларым, ашыкмагыз. Ишекне ачканчы кем икәнен сорагыз. Тавышын танийсызмы?

**Барсы бергә:** Кем бар анда?

**Тәрбияче:** Бәлки явыз бүредер анда?

**Хат ташучы:** мин хат ташучы. Сезгә посылка алып килдем. Тизрәк ишекне ачыгыз.

**Барсы бергә:** Ура. Ура. Безгә посылка килгән.

**Куян:** Туктагыз, туктагыз. Ишекне ачырга ашыкмагыз. Безгә бу тавыш таныш түгел. Ә таныш булмаган кешеләргә ишек ачырга ярамый.

**Тавык:** Хат ташучы, гафу ит, ләкин без сиңа ишек ача алмыйбыз. Кич белән кил. Әни өйдә була.

**Тәрбияче:** балалар, тавык дөрес әйтә бит. Таныш булмаган кешеләргә без ишекне ачабызмы? Ә сез танышларыгызның тавышларын танийсызмы? Әйдәгез, түгәрәккә басыгыз да, “Тавышыннан таны” уенын уйныйбыз.

(төлке баласы кадак бн уйнап утыра)

**Тәрбияче:** балалар , сез төлкене күрмәдегезме?

**Эт:** карагыз әле, төлке кадак тапкан. Ой, ой,ой. Розеткага якынлаша түгелме?

**Төлке:** розеткада ниләр бар икән? Кадакны тыгып карыйм әле.

**Тиен:** Тукта, син нишлисең? Исеңдә тот: беркайчан да розетка янына барма.

**Аю:** ә кадакны розеткага тыксаң, ток суга.

**Төлке:** Аңладым, аңладым, дусларым. Бүтән беркайчан да розеткалар бн уйнамам.

(ут сүнә)

**Куян:** ни булды? Ник ут сүнде?

**Тиен:** Тынычланыгыз, хәзер мин шәм кабызам. Минем кесәмдә шырпы бар.

**Аю:** Ура. Шәмне кабызабыз. Якты була.

**Тәрбияче:** Шырпыдан ялкын идәнгә төште. Идәннән ут пәрдәләргә кабып өскә үрмәләде. Җәнлекләр куркуларыннан, качып беттеләр.

**Куян:** Дусларым, чыгыгыз качкан җирләрегездән.

**Тәрбияче:** Җәнлекләр, сез исән-саумы? Әйдәгез куянга янгын сүндерүчеләрне чакырырга ярдәм итик. Нинди номер җыярга кирәк? (җаваплар тыңлана)

**Куян:** Өтәч абый, безгә килегез.Янгыннан коткарыгыз. Без урман аланында, нәни йортта яшибез.

**Тәрбияче**: Балалар , әйдәгез, янгынны сүндерергә ярдәм итик.

**"Янгынны сүндер" уены.**

**Өтәч керә:**

Ут белән уйнарга ярамый! Шырпы да, шәм дә балаларга уенчык түгел. Ә инде янгын чыкса, тизрәк олыларны һәм янгын сүндерүчеләрне чакырырга кирәк.

Янгын сүндерүчеләрне нинди номер буенча чакырабыз?Исегездә калдырыгыз, балалар, ут белән беркайчан да уйнарга ярамый!

**Тәрбияче:** Менә шулай, Куянкай аның дуслары төрле хәлләргә очраганнар. Мондый очраклар булмасын өчен, куркынычсызлык кагыйдәләрен онытмаска кирәк. Балалар, беркайчан да бу кагыйдәләрне онытмагыз.

## Йомгаклау

Эшчәнлек барышында балалар  куркынычсызлык кагыйдәләрен әкият геройлары – урман җәнлекләре ролендә күрсәтеп бирделәр. Төрле куркыныч хәлләргә очраган җәнлекләр, бу ситуациядән чыгу юлын эзләделәр һәм куркынычсызлык кагыйдәләрен кабатладылар. Эшчәнлек барышында көндәлек тормышта очрарга мөмкин очраклар каралды. Даруларны өлкәннәрдән башка кабарга ярамый, таныш булмаган кешеләргә ишек ачмыйбыз, розеткага әйберләр тыгарга ярамый, ут белән уйнау янгынга китерә, кебек кагыйдәләр кабатланды.

## Кулланылган әдәбият исемлеге


1. http://sabyem.ru/?cat=184